Татарстан Республикасы
Сарман муниципаль районы
Мортыштамак гомуми урта белем бирү мәктәбе

# АЧЫК ДӘРЕС

*"Урман һәм кеше. Урманда үз-үзеңне тоту кагыйдәләре"*
*4 нче класс*

*предмет: әйләнә тирәбездәге дөнья, ТИН*

*Укытучы: Газизова Гүзәлия Фирдәвис кызы*

*Үткәрелде: 18.10. 2006 РМО*

# Әйләнә - тирәбездәге дөнья

**Тема: Урман һәм кеше. Урманда үз-үзеңне тоту кагыйдәләре (ТИН)**

**Дәрес максаты:**

1. Укучыларның урман зонасы, Россия территориясендәге урман төрләре, алардагы хайван һәм үсемлек дөньясы турындагы белемнәрен ныгыту, гомумиләштерү. Табигатьттә һәм кеше тормышында урманның әһәмиятен, аның компонентлары арасында булган бәйләнешләрен күрсәтү. Урман зонасындагы экологик проблемалар, аларны чишү юллары белән таныштыру.

2. Укучыларның хәтерен, игътибарын, логик фикерләү сәләтен үстерү.

3. Табигатькә һәм әйләнә-тирә дөньяга сакчыл караш тәрбияләү. Матурлыкны күрә, аның белән соклана белергә өйрәнү. Туган-як табигатенә карата мәхәббәт тәрбияләү.

**Җиһазлау:** А.А Плешаков, Е.А Крючкова “Әйләнә - тирәбездәге дөнья” (1 нче кисәк, 4 нче сыйныф. Рәсемнәр, плакатлар, биремнәр, табышмаклар, “Кызыл китап”, дәфтәр, ручка, карандаш, магнитофон, кассета.

**Дәрес барышы:**



**I. Оештыру моменты:**

| Укытучы: | Укучылар: |
|---|---|
| - Исәнмесез, балалар.<br>Бүгенге табигать белеме дәресендә сезне кызыклы мажаралар көтә, чөнки без сезнең белән сәяхәткә кузгалабыз. Ләкин юлга чыгар алдыннан һава торышын белергә кирәк.<br>- Көз турында халык авыз иҗатыннан берничә мисал китерә (әйтем, сынамышлар..) | - Ел фасылы, табигатьтәге үзгәрешләр, һава торышы турында сөйлиләр |

## II. Белемнәрне актуальләштерү.

<table>
<tr>
<td>Балалар, безнең сыйныф исеменә серле хат килде. әйдәгез әле, конвертны ачып, хатның эчтәлеге белән танышыйк.</td>
<td>- Хатны укый:<br>Исәнмесез, Ирек һәм Айзилә! Миңа сезнең күп белүегез, табигатьне яратуыгыз турында сөйләделәр. Шуңа күрә сезгә ярдәм сорап язарга булдым. Безнең урманга куркыныч яный, аны тих арада коткарырга кирәк. Моны сез генә эшли аласыз.<br>Сезне түземсезлек белән көтеп калам.<br>Сәлам белән Шүрәле.</td>
</tr>
<tr>
<td>- Балалар, сез урманны коткарыргы әзерме?<br>- Әйдәгез әле юлга чыкканчы урманнар турында белемнәребезне искш төшерик.<br>1) Ылыслы урманнар нинди урман зонасын барлыкка китерә?<br>2) Ылыслы һәм яфраклы агачлар үсә торган урманнарны ничек атыйлар?<br>3) Катнаш урманнардан көньяктарак нинди урман сузылган?</td>
<td>- Әйе, әзер!<br><table><tr><td>Т</td><td>А</td><td>Й</td><td>Г</td><td>А</td><td></td><td></td></tr><tr><td>К</td><td>А</td><td>Т</td><td>Н</td><td>А</td><td>Ш</td><td></td></tr><tr><td>Я</td><td>Ф</td><td>Р</td><td>А</td><td>К</td><td>Л</td><td>Ы</td></tr></table></td>
</tr>
<tr>
<td>- Кроссвордны дөрес чиштегез, балалар. ә хәзер шушы сүзләргә карап нинди нәтиҗә ясыйбыз?</td>
<td>- Тайа, катнаш, яфраклы урманнар урман зонасын барлыкка китерә (картада күрсәтү)</td>
</tr>
<tr>
<td>- Ә хәзер балалар, үткән теманы кабатлыйбыз. Россия урманнары турында сөйләп алабыз.</td>
<td>- Урман зонасы Россия территориясенең яртысыннан артыгын били. Табигать шартларына карап, көньякка таба урманнарның төре, андагы үсемлек һәм</td>
</tr>
</table>

| | |
|---|---|
| | хайваннары дөньясы да үзгәрә (тайга – катнаш – киң яфраклы урманнар) |
| Эш дәфтәрендә:<br>- буялган хайван исемнәрен атау<br>- үсемлекләрне карау<br><br>Балалар, карагыз әле, аңа чыннан да куркыныч яный икән, агачлары да сирәгәйгән.<br>- Моның өчен сезгә бер якка ылыслы, икенчегә - яфраклы агачларны утыртырга кирәк. (укучыларга ылыслы һәм яфраклы агачлар исеме язылган битләр таратыла, аларны аерып куялар).<br><br>III. Яңа тема.<br>- Дөрес эшләдегез. Урманның табигатьтә һәм кеше тормышында әһәмияте бик зур. Аларны “безнең планетаның үпкәсе” дип тә атыйлар. Чөнки урман үсемлекләре күп күләмдә кислород бүлеп чыгара һәм углекислый газ йота. Урман һаваны тузаннан чистарта. Шулай ук күп агачларның яфраклары үзенчәлекле матдәләр – фитонцидлар бүлеп чыгара. Алар төрле зарарлы бактерияләрне үтерә. Урман – сулыклар һәм туфракның да сакчысы. Урманнарда кар һәм яңгыр | - Дөрес. Шулай итеп без сезнең белән урманга да килеп җиттек (Урман рәсеме эленә)<br><br>**Ылыслы** **Яфраклы**<br>чыршы имән<br>нарат өрәңге<br>карагай юкә<br>кедр каен<br><br>- Фитонцид |

| | |
|---|---|
| сулары туфракка акрын сеңә, шунлыктан су ташкын булып акмый, елганы акрынлап “туендыра”, туфракны җимерми.<br><br>Тактада схема ясала ⟶ | <br> |
| - Урман алалындагы чәчәкләрнең берсен таптап киткәннәр, ул шиңгән. сез дөрес җавап бирсәгез, ул терелер.<br><br>1) Кайсы агачтан пианино ясыйлар?<br>2) Нинди агачны шәһәрдә күбрәк утырталар?<br>3) Шырпыны нинди агачтан ясыйлар?<br>Укучылар җавап бирделәр.<br>- Чәчәкнең таҗлары күтәрелә, ачыла.<br><u>Физкультминутка</u>. Әйдәгез әле, балалар, бергәләп ял итеп алабыз. Урманның матурлыгы белән сокланыйк, кошлар тавышын тыңлыйк. Саф һава сулыйк (сулыш алу гимнастикасы). | <br> |
| V. <u>Ныгыту</u>:<br>Кеше табигать белән тыгыз бәйләнештә һәм аңа турыдан-туры тәэсир итә. Урман зонасандагы экологик проблемалар аны ерткычларча файдалану: кисүгә, чамасыз | - Үзагачы өчен. Ул елдан-ел күбрәк кирәк. Аннан төзү материаллары, кәгазь, ясалма тукыма һә тире, фото- һәм кинопленка, лаклар, буяулар, |

| | |
|---|---|
| аулауга һәм браконьерлыкка бәйле.<br>- Ни өчен агачлар киселә?<br>- Аларның әзәюен туктату өчен нәрсә эшләргә кирәк?<br><br>- Әйе, балалар. Дөрес. Урмандагы күп кенә үсемлекләр һәм хайваннар ник юкка чыга, аларның саннары кими? Алар турында сез кайдан белә аласыз? Нинди урман үсемлекләре һәм хайваннары "Кызыл китапка" кертелгән?<br><br>- Алар катгый сак игълан ителү нәтиҗәсендә генә саклап калынган. Моның өчен урман зонасында тыюлыклар төзелгән. Мәсәлән, <u>Ока буе – Терраса тыюлыгы.</u><br>- Укучылар, урманга баргач, нинди мөһим кагыйдәләрне үтәргә кирәк?<br><br>Учак ягу кагыйдәләре белән танышалар: 111 бит. Нинди тема? Урман һәм аның әһәмияте? Андагы экологик проблема? Аны булдырмас өчен нишләргә тиеш?<br>- Дәрестә урман белән кеше әһәмиятенә, бәйләнеш белән таныштык. Экологик проблемаларны карадык, урманда үзеңне | пластмассалар һәм башка кирәкле әйберләр җитештерәләр. әзерләнгән агачны тулысынча файдаланырга, кискән агач урынына яңаларны утыртырга.<br><br>- Кешеләрнең чамасыз аулавыннан.<br>- Кызыл китапка: (дәреслек 109 бит) сары бамакчык, женьшень, коңгыз, болан-коңгыз, мандаринка үрдәк, зубр, Амур юлбарысы. (танышалар).<br><br><u>Дәреслек белән эш</u><br><br>- Чүпләмәскә<br>- Агачлар, чәчәкләрне сындырмаска<br>- Хайваннарны ауламаска<br>- Учак якмаска<br>(эмблема куеп барыла). |

4нче сыйныфта 2 укучы. 2се дә алдынгылар булып укыганнар. Солтанова Айзилә һәм Лотфуллин Ирек, икесе дә тырыш укучылар, түгәрәкләргә даими теләп йөриләр. Мин аларны быел гына укытам. Минем проблема “Экологик культура аша укучыларның рухи һәм физик үсешенә ирешү”, шуңа күрә мин әйләнә-тирәбездәге дөнья белән танышу дәресен алдым.

Тема: Урман һәм кеше. Урманда үз-үзеңне тоту кагыйдәләре.

Максат: 1. Укучыларның урман зонасы, Россия территориясендәге урман төрләре, алардагы хайван һәм үсемлек дөньясы турындагы белемнәрен ныгыту, гомумиләштерү. Табигатьттә һәм кеше тормышында урманның әһәмиятен, аның компонентлары арасында булган бәйләнешләрен күрсәтү. Урман зонасындагы экологик проблемалар, аларны чишү юллары белән таныштыру.

2. Укучыларның хәтерен, игътибарын, логик фикерләү сәләтен үстерү.

3. Табигатькә һәм әйләнә-тирә дөньяга сакчыл караш тәрбияләү. Матурлыкны күрә, аның белән соклана белергә өйрәнү. Туган-як табигатенә карата мәхәббәт тәрбияләү.

Дәрес планын класстагы укучыларның үсеш дәрәҗәсенә туры китереп төзедем. Җиһазлау өйрәнелә торгантема туры килерлек итеп булдырылды: дәреслек, рәсемнәр, карта, биремнәр, сынамышлар. Дәрес оешкан төстә башланып китте. Укучыларның әзерлеге тикшерелде. Табигать белемен өйрәнүдә зур әһәмияткә ия булган һава торышы тасвирланды. Дәрес яңа тема өйрәнүгә багышланган. Ул 7 өлештән тора: I. Оештыру моменты, II. Белемнәрне актуальләштерү - өй эшен тикшерү, III. Яңа тема, IV. Физкульминутка, V. Ныгыту, VI. Йомгаклау, VII. Өй эше. Һәрбер өлештә алдан куелган максатка ирешелде. Укучыларның үткән материалны үзләштерү дәрәҗәсен тикшерү кызыклы һәм нәтиҗәле үтсен өчен кроссворд чишү һәм әңгәмә кулланылды. Балаларның үткән теманы әйбәт үзләштерүе яңа тема өйрәнүгә нигез булып торды. Дәрес уен-бирем формасында оештырылган иде. Бу аларны табигатькә, тереклеккә һәм аны саклауга багышланган темага

| | |
|---|---|
| тоту кагыйдәләрен белдек.<br>V. Йомгаклау.<br>- Бүгенге дәрес сезгә ошадымы? Ни өчен? Нәрсәләр белдек?<br>Бәяләү (билгеләр кую).<br>VII. Өй эше: 106-111нче битләр, сорауларга җавап бирергә, дәфтәрдә Кызыл китапка кертелгән хайван, үсемлекләрне язарга. | |

якынайта, аларның фикерләү дәрәҗәсен үстерә. Яңалык белән танышу алар өчен кызыклы һәм мавыктыргыч итеп үтә.

- Яңа материалны өйрәнү балаларга төрле биремнәр эшләшү, урманның әһәмияте модельләштерү рәвешендә, укытучының аңлашуы белән бәйләнеп барды. Бу укучыларның дәрескә игътибарлылыгын, кызыксынучанлыгын арттырды, укучы – укытучы бәйләнешен ныгытты, яңа теманы үзләштерүне җиңеләйтте
- Дәрес барышында төрле күргәзмә әсбаплар кулланылуы аны җанландырып җибәрде, укучыларның хәтерен ныгытуда, хыялый фикерләүләрен үстерүдә ярдәм итте.
- Дәреслек белән эшләү нәтиҗәсендә яңа теманы кабатлау, тирәнрәк аңлау ныгыту кебек максатларга ирешелде.
- Йомгаклау өлешендә укучыларның нәтиҗә ясаулары буенча теманы әйбәт үзләштерүләре ачыкланды. Өй эшен үтәү буенча киңәшләр бирелде.

Гомумән, дәрестә үзем куйган максатка ирештем.